| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ**<br>**13.12.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 14** |

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 153, 265 статьяларына, 2011 елның 07 февралендәге «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 6 – ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Совет шәһәре Зеленодольск карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Гамәлдәге законнар нигезендә тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тапшыру турында килешү төзергә.

3. Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкаруга тапшырыла торган бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү методикасын 1 нче кушымтада каралганча расларга.

4. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме Тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкаруга тапшырыла торган бюджетара трансфертларның еллык күләмен билгеләү методикасы нигезендә исәпләнә, әлеге карарның 2 пункты буенча төзелә торган килешү шартлары белән аныклана дип билгеләргә.

5. Зеленодольск шәһәре Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип таныргa:

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча ревизия комиссиясе вәкаләтләрен «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2015 елның 9 февралендәге 306 номерлы;

- 2025 елның 21 мартындагы «Зеленодольск шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегенең тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру буенча ревизия комиссиясе вәкаләтләрен «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2015

елның 9 февралендәге 306 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»185 номерлы.

6. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат (https://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми (https://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск шәһәре Советының социаль-икътисадый үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре, муниципаль милек һәм эшкуарлыкны үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**